Муниципаль бюджет мәгариф учреждениеләрен бетерү турында

«Россия Федерациясендә бала хокукларының төп гарантияләре турында» 1998 елның 24 июлендәге 124-ФЗ номерлы Федераль законы, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Законның 22 статьясының 5 өлеше нигезендә, Чүпрәле муниципаль районы Уставының 44 статьясына таянып, салым органнарында юридик затлар турындагы белешмәләрне актуальләштерү максатларында Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2018 елның 1 июленнән юкка чыгарырга:

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «Чуаш Бизнәсе балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе;

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «Яңа Шигали башлангыч гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль гомуми белем бирү учреждениесе;

2. Муниципаль бюджет мәгариф учреждениеләрен бетерү буенча комиссия төзергә һәм аның составын кушымта нигезендә расларга.

3. Муниципаль бюджет мәгариф учреждениеләренең ликвидация комиссиясе җитәкчесенә түбәндәгеләрне йөкләргә:

- ТР буенча 8 нче Федераль салым хезмәтенең районара инспекциясенә муниципаль бюджет мәгариф учреждениеләрен бетерү турында әлеге карар кабул ителгән көннән алып өч көн эчендә законнарда билгеләнгән тәртиптә хәбәр итәргә;

- Татарстан Республикасы буенча «Вестник государственной регистрации» журналының региональ вәкиллегендә муниципаль бюджет мәгариф учреждениеләрен бетерү турында игълан (хәбәр итүне) бастырып чыгаруны тәэмин итәргә;

- муниципаль бюджет мәгариф учреждениеләре мөлкәтенә инвентаризация үткәрергә һәм аны вәкаләтле органга тапшырырга;

- эштән азат ителү датасына 2 ай кала муниципаль бюджет мәгариф учреждениеләре хезмәткәрләрен хезмәт законнары нигезендә азат итү чараларын гамәлгә ашырырга;

- муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесен закон белән билгеләнгән тәртиптә юридик затларның Бердәм дәүләт реестрыннан төшереп калдыру буенча чаралар күрергә.

4. «Муниципаль бюджет мәгариф учреждениеләрен бетерү турында» Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 22 декабрендәге 643 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

5. Әлеге карарны Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында Интернет челтәрендә урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе М.Р. Гафаров

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның "___"________________ ___ номерлы карарына кушымта

Ликвидация комиссиясе
составы

| | |
|---|---|
| Ахметов С.Л. | «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесе методисты, комиссия рәисе, җаваплы ликвидатор |
| Яфизова Р.Ф. | Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы «Үзәкләштерелгән бухгалтерия» муниципаль казна учреждениесе җитәкчесе |
| Абдреев И.Т. | Чүпрәле муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе (килешү буенча) |

Башкарма комитет
эшләр идарәчесе Д.Р. Сабирзянова